**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре № 282-38 «20» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 15.03.2012 №117-18 «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халкы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халык мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында
(29.09.2017 №136-21 карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 26.02. 2019 ел № 127 карары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 15.03.2012 №117-18 «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халкы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халык мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турындагы Нигезләмәгә (29.09.2017 №136-21 карар редакциясендә) үбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең 1 пунктын «Азнакай районының» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегендә каралган очраклардан тыш» сүзлзре белән тулыландырырга;

3 пунктның 2 һәм 9 пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» : http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен Азнакай район Советының законлылык, хокук

тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин